Бүгенге санда

Шикәр заводында кызу сезон бара. 3 бит.

Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга **25** сентябрь 2015 ел

№ 70 (10599)

26 сентябрьгә һава торышы: аяз һава, алмашынучан җил, 1-2 м/с; температура көндез +25°С, төнлә +14°С

Равил Кузюров:

“Сезнең ышаныч – зур җаваплылык”

Автор фотосы

РАВИЛ КУЗЮРОВНЫ РАЙОН БАШЛЫГЫ ВАЗИФАСЫНА САЙЛАНУЫ БЕЛӘН КОТЛАДЫЛАР

Яңа сайланган район Советының дүшәмбе көнне үткән беренче сессиясе, традиция буенча, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшенә эшлекле тон бирде.

Сессия эшендә ТР Дәүләт Советы депутатлары Марат Шаһитов, Мөхәммәтвәли Хөснетдинов, урман хуҗалыгы министры вазифаларын башкаручы Алмас Нәзиров һәм башкалар катнашты. Үткән сайлаулар турында мәгълүмат белән район территориаль сайлау комиссиясе рәисе Лилия Шакирова чыгыш ясады. Алга таба сессиядә Алмас Әминович нурлатлыларга сайлау кампаниясен уңышлы үткәрүләре өчен ТР Президентының рәхмәтен белдерде. Аннан соң ул ике ел дәвамында район белән уңышлы җитәкчелек итүен, күп кенә социаль мәсьәләләрне хәл итүгә керткән өлешен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты исеменнән Равил Кузюров кандидатурасын район белән җитәкчелек итү өчен тәкъдим итте. Әлеге кандидатураны район вәкилләре Дамир Ишкинеев һәм Надежда Егорова да хупладылар. Яшерен тавыш бирү барышында район Советы депутатлары район башлыгы вазифасына бертавыштан Равил Кузюровны сайладылар. Район башлыгы ант сүзләрен укыды, муниципаль берәмлек җитәкчесе вазифасын зур җаваплылык буларак кабул итүен ассызыклап, республика җитәкчелегенә һәм нурлатлыларга күрсәтелгән ышанычлары өчен рәхмәт белдерде.

Район башлыгы урынбасары итеп бертавыштан Флюра Ногманова сайланды. Биредә үк депутатлар контроль-хисап палатасы рәисен билгеләү, район Советы комиссияләрен оештыру, район башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында карарлар кабул иттеләр.

Беренче сессия яңа оешкан Советның эш ориентирларын билгеләде.

Өченче чакырылыш район Советы формалашты. Депутатларның билгеләнгән саны 54 кеше тәшкил итте. 6 даими комиссиягә бүленеп, алар сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф, сәнәгать, торак-коммуналь хуҗалык, хокук саклау, җирле үзидарә һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендә эшләячәкләр.

Валентина ВАФИНА

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

РАЙОНДА КОРБАН ГАЕТЕ ҮТТЕ

Кичә район башлыгы Равил Кузюров мөселманнарны ислам дөньясындагы ике зур бәйрәмнең берсе - Корбан гаете белән котлады. Бу көнне районның барлык мәчетләрендә гает намазы, хөтбә, вәгазь укылды. Нурлаттагы яңа төзелеп килүче “Миннегөл” мәчете дә гаетне беренче тапкыр зурлап уздырды.

“МИЛЛӘТЛӘР КРОССЫ” ЧАКЫРА

Бу якшәмбедә нурлатлылар “Милләтләр кроссы”на кушыла. Әлеге акция - Россия территориясендә үткәрелә торган, катнашучылар ягыннан да, географиясе буенча да иң күләмле спорт чарасы. Массакүләм спорт чарасында район предприятиеләре физик культура коллективлары, мәктәп укучылары, район халкы катнаша ала. Ярышлар **27 сентябрьдә 10 сәгатьтә аэропорт территориясендә башлана.**

ЯРМИНКӘГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Иртәгә, 26 сентябрь көнне, иртәнге 7дән Гыйматдинов урамының үзәк өлешендә Өлкәннәр көненә багышланган авыл хуҗалыгы ярминкәсе гөрләячәк. Бу көнне шәһәрләләргә чамалы бәяләрдән ит, сөт, сөт ризыклары, бөртек, бәрәңге, яшелчәләр һәм башка продукция киң ассортиментта тәкъдим ителәчәк. Өлкәннәр хөрмәтенә зур концерт, авыл җирлекләре өстәлләрендә кайнар чәй оештырыла, ә волонтерлар олыларга ярдәм күрсәтәчәк.

ХЕЗМӘТКӘ – ХӨРМӘТ

Республиканың массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен “Татмедиа” акционерлык җәмгыяте филиалы “Дуслык” (“Дружба”, “Туслах”) газетасы редакциясе” директоры – баш мөхәррир-ебез **ХӘЙРУЛЛИНА Сәкинә Нурулла кызына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ӘБУНӘ ДӘВАМ ИТӘ

БЕЗ СЕЗНЕ ПОЧТАДА ҺӘМ РЕДАКЦИЯДӘ КӨТӘБЕЗ.

АКТУАЛЬ

Каешларны автокәнәфигә алмаштырабыз

ЮХИДИ хезмәткәрләре сентябрь ае башыннан яңа кагыйдәләр буенча эшлиләр.

– Узган атнада безгә баланы адаптер каешы белән эләктереп йөрткән өчен 3 мең сум штраф салдылар, ә шул көннәрдә такси шоферына адаптер өчен 3 мең сум штраф бирделәр, – ди Гөлназ Фәхриева. – Әлеге яңалык турында бернинди аңлату эшләре дә булмады, инспекторлар үзләре дә җүнләп берни әйтә алмыйлар.

ЮХИДИ бүлегендә хәбәр итүләренчә, закон яңа үзгәрешләр “Российский Красный Крест” һәм Россиянең Автомобиль һәм автомотор фәнни-тикшеренү институты тарафыннан кертелгән.

Яңа үзгәрешләр буенча пассажир балалар бары махсус автокәнәфиләрдә генә йөртелергә тиеш. Белгечләр адаптер фиксаторының пассажир бала өчен зарарлы булуын хәбәр итте. Фиксатор баланың эчке органнарына, умыртка баганасына зыян сала икән. Ә менә автокәнәфиләрне балалар шәхси тәхетләре итеп кабул итәләр.

– Автокәнәфиләр иминлек ягыннан бик шәп, әлбәттә, - ди яшь әти Евгений. – Тик аның да үз минуслары бар. Җәен балага автокәнәфиләрдә кызу, кышын бераз кысырыграк. Аннан кәнәфи бик җиңелләрдән түгел, аны күтәреп йөртәсе бар, өстәвенә, бәясе дә кыймәт!

– Әти-әниләр балаларын машинада йөрткәндә, баланың физик параметрларыннан чыгып эш итәргә тиеш. 12 яшькә кадәр дигән яшь нормасы искерде инде, - ди ЮХИДИнең пропаганда инспекторы Ринат Мөгайнетдинов. – Өстәмә ориентир – баланың буе 150 сантиметрга кадәр икән, ул кәнәфигә утыртылырга тиеш. Хәзерге заманда балалар бик тиз үсәләр, 11 яшьлек үсмер 150 сантиметрдан узып китәргә мөмкин. ДПС инспекторына баланың буен рулетка белән үлчәве җиңелрәк, һәр әти – әни үзләре белән туу турындагы таныклык йөртә алмый бит.

Әлеге яңалыкны мәҗбүр итү түгел, ә ныклы иминлек чарасы дип кабул итү кирәктер. Әгәр бала белән берәр хәл була калса, язмыш үзе бар гомергә штраф салачак бит.

Зилия ӘКСАНОВА

РАЙОН ТОРМЫШЫ

Беренче сессия үтте

Дүшәмбе көне Нурлат шәһәре Советының оештыру сессиясе үтте.

Анда Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры вазифаларын башкаручы Алмас Нәзиров та катнашты.

Сессияне шәһәр Советының иң өлкән депутатларыннан берсе Евгений Савинов алып барды. Шәһәр Уставы нигезендә, яңа сайланган Советның беренче сессиясендә вазифаларга бәйле җаваплы карарлар кабул итәргә кирәк иде. Беренче мәсьәлә – Татарстан Республикасы Президентлыгына, "Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге вәкиллекле органнарына сайлауларның нәтиҗәләре турында шәһәр территориаль сайлау комиссиясе рәисе Линар Маняпов чыгыш ясады. Ул сайлауларның югары дәрәҗәдә узуын, сайлау комиссияләренең оешкан төстә эшләүләрен билгеләп үтте, депутатларга таныклыклар тапшырды. Алмас Нәзиров Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов исеменнән республика Президентын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча сайлау кампаниясенең уңышлы тәмамлануы белән котлады. Биредә үк ул Нурлат шәһәре Уставы нигезендә, Татарстан Президенты исеменнән депутатлар каравына Равил Кузюров кандидатурасын шәһәр башлыгы итеп сайлау өчен тәкъдим итте.

Шәһәр Советына 12нче Нурлат-Космонавтлар сайлау округыннан кандидат, шәһәр Советында "Бердәм Россия" партиясеннән төркем җитәкчесе Илдар Зәкуанов төркем әгъзаларының Татарстан Президенты тарафыннан шәһәр башлыгы вазифасына тәкъдим ителгән кандидатураны тулысынча хуплауларын әйтте.

– Җирле бүлекчә конференциясендә шәһәр башлыгы вазифасына кандидатура буларак Равил Әфраим улы Кузюров сайланды, - диде ул.

Сессиядә башка тәкъдимнәр кермәде.

– Рөстәм Нургалиевичка миңа күрсәткән югары ышанычы һәм хуплавы өчен зур рәхмәт, - дип мөрәҗәгать итте Нурлат шәһәре башлыгы вазифасына кандидат Равил Кузюров һәм шәһәр активы белән нәтиҗәле уртак хезмәттәшлеккә ышаныч белдерүен әйтте.

ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ РӘИСЕ ЛИНАР МАНЯПОВ ДЕПУТАТЛАРГА ТАНЫКЛЫКЛАР ТАПШЫРДЫ

Көн тәртибендәге икенче мәсьәлә Нурлат муниципаль районы Советына шәһәр Советыннан вәкил сайлау турында иде. Депутатлар 13нче Нурлат-Гыйматдинов сайлау округыннан депутат Роман Чахмахчевны күрсәттеләр.

Тәкъдим ителгән Равил Кузюров һәм Роман Чахмахчев кандидатураларын депутатлар бердәм тавыш белән сайладылар. Аннан соң Равил Әфраимович, җирлек Уставы нигезендә, ант тотты, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, Нурлат шәһәре Уставын истә тотарга, шәһәр халкының имин тормышын тәэмин итүгә бөтен көч һәм белемнәрен куярга вәгъдә бирде.

Алга таба сессия эше белән шәһәр башлыгы Равил Кузюров җитәкчелек итте. Сессиянең көн тәртибендә каралган соңгы – Нурлат шәһәре Советы даими комиссияләре турындагы мәсьәләне караганчы, ул депутатларга күрсәтелгән ышанычлары өчен рәхмәт белдерде.

– Муниципаль берәмлек җитәкчесе вазифасын, иң беренче чиратта, халык алдында зур җаваплылык буларак кабул итәм. Ышанычыгызны аклау өчен барын да эшләячәкмен, - диде ул.

Биредә шулай ук дүрт даими комиссия булдырырга дигән карар кабул ителде.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

БЕР УЧ ХӘБӘР

САЙЛАУ КАМПАНИЯСЕНӘ ЙОМГАК ЯСАДЫЛАР

Дүшәмбе көнне "Бердәм Россия" сәяси партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе XXI конференциясенең өченче этабы үтте.

Конференциядә делегатлар бүлекчәнең җирле үзидарә вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча сайлау кампаниясенә нәтиҗәләр ясадылар. Нурлат җирле бүлекчәсе сәяси Советы әгъзасы Флюра Ногманова бердәмроссларның сайлауларда активлык күрсәтүләрен аерым билгеләп үтте.

– Сайлауларга әзерлек чорында бердәмросслар халык арасында зур эш алып бардылар. 27 мәйданчыкта праймеризлар узды, авылларда халык җыеннары һәм шәһәрдә гражданнар белән очрашулар зур активлык белән үтте. Сайлауларда халык күпчелек тавышны "Бердәм Россия"гә биреп, үз ышанычын белдерде. Партиянең бәхәссез җиңү яулавы алга таба да сайлаучыларның ышанычын аклап эшләүне бурыч итеп куя, – диде ул.

Конференция делегатлары бүлекчәнең сайлауларга әзерлек буенча эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Шунда ук делегатлар җирле сәяси Совет составына үзгәрешләр дә керттеләр. Сәяси совет әгъзалары Рәмзия Сингатуллина белән Аркадий Клементьев урынына Сергей Белов белән Әлфия Галәветдинова сайланды. Соңрак яшерен тавыш бирү юлы белән альтернатив нигездә муниципаль берәмлек башлыгы – "Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Советы рәисе вазифасына кандидат итеп Равил Кузюровны сайладылар.

Конференцияне бүлекчә секретаре Равил Кузюров алып барды, аның эшендә ТР Дәүләт Советы депутаты, "АК БАРС Банк" идарә рәисе беренче урынбасары Марат Шаһитов катнашты.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

Җәмәгать тыңлаулары билгеләнде

Нурлат муниципаль районы башлыгы Р.Ә.Кузюровның 2015 елның 22 сентябрендәге № 65 карары белән җир участокларын файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары билгеләнде:

– Илнар Илдус улы Фәхретдиновка – Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Төньяк-Көнчыгыш мкр., 34 поз. адресы буенча урнашкан 16:56:010115:649 кадастр номерлы 1012 кв. метр мәйданлы, Ж1 (индивидуаль торак йортлар төзелеше) зонасында урнашкан җир участогының шартлы рәвештә файдаланыу рөхсәт ителгән төрен амбулатор-поликлиника учреждениеләре, практика табиблары кабинетлары өчен;

– Мөхәммәтҗанова Минниса Вәлиәхмәтовна, Мөхәммәтҗанов Дамир Альбертович исеменнән эш йөртүче Мөхәммәтҗанов Альберт Наилевич, Мөхәммәтҗанова Линара Альбертовнага – Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Дружба ур., 33 адресы буенча урнашкан 16:56:010128:332 кадастр номерлы 149 кв. метр мәйданлы, Ж1 (индивидуаль торак йортлар төзелеше) зонасында урнашкан җир участогының шартлы рәвештә файдаланыуга рөхсәт ителгән төрен аерым торучы бинада, торак йортлар эченә кертеп төзелгән яки торак йортлар эченә кертеп-янәшә төзелгән ваклап сату объектлары - беренчел кирәк-ярак товарлары кибете өчен.

Җәмәгать тыңлауларын 2015 елның 15 октябрендә 14.00дә Совет ур., 98 адресы буенча, Нурлат муниципаль районы Советының кече залында үткәрү билгеләнгән. Җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашуга заявкалар 2015 елның 11 октябренә кадәр Нурлат шәһәре, Совет ур., 117 (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге, 2-06-91, 2-38-55) адресы буенча кабул ителәчәк. Җәмәгать тыңлауларына куела торган мәсьәлә буенча Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең административ бинасында (Нурлат, Совет ур., 96) экспозиция оештырыла, физик һәм юридик затлардан тәкъдимнәр, киңәшләр һәм заявкалар кабул ителәчәк.

Әлеге карарның тулы тексты Нурлат муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган.

Юристлар түләүсез ярдәм күрсәтә

Бүген, 25 сентябрь – Бөтенроссия түләүсез юридик ярдәм көнендә "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе җәмәгать кабул итүе бүлмәсендә (Пушкин урамы, 46) кабул итү оештырыла. Биредә иртәнге 8дән кичке 4кә кадәр юристлар, нотариуслар һәм прокуратура хезмәткәрләре нурлатлыларга юридик мәсьәләләр буенча түләүсез консультацияләр бирәләр.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

№2 **21 сентябрь 2015 ел**

"Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 36нчы маддәсе, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28.07.2004 елгы №45-ЗРТ законның 24нче маддәсе, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 37нче маддәсе, санау комиссиясе утырышының яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы 21.09.2015 елгы №2 беркетмәсе нигезендә, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге вәкәләтле органы карар бирде:

1."Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башлыгы итеп Равил Әфраим улы Кузюровны сайларга.

2.Әлеге карар аны кабул иткән көннән гамәлгә керә.

Гәйтән авыл җирлегеннән ТР Нурлат муниципаль районы Советы депутаты, рәислек итүче А.Л.КЛЕМЕНТЬЕВ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

№3 **21 сентябрь 2015 ел**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгы урынбасарын сайлау турында

Нурлат муниципаль районы Уставының 41нче маддәсе нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы карар бирде:

1.Нурлат муниципаль районы башлыгы урынбасары итеп Нурлат муниципаль районы Советы депутаты Флюра Рәшит кызы Ногманованы сайларга.

2.Әлеге карар аны кабул иткән көннән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы рәисе Р.Ә.КУЗЮРОВ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

№4 **21 сентябрь 2015 ел**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисен билгеләү турында

Нурлат муниципаль районы башлыгының районның Контроль-хисап палатасы рәисе вазифасына М.В.Ибраһимова кандидатурасын тәкъдим итүен карап, "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" 2011 елның 7 февралендәге №6-ФЗ Федераль законы, Нурлат муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2013 елның 30 апрелендә расланган №229 Карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы карар бирде:

1.2015 елның 21 сентябреннән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе вазифасына Ибраһимова Марина Вячеславовнаны билгеләргә.

2.Әлеге карар аны кабул иткән көннән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы рәисе Р.Ә.КУЗЮРОВ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАРЫ

№5 **21 сентябрь 2015 ел**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Нурлат шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең вәкәләтләре туктатылу, Нурлат шәһәре Советы вәкәләтләренең вакыты чыгу сәбәпле, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 37нче маддәсе, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28.07.2004 елгы №45-ЗРТ законның 26нчы маддәсе, Татарстан Республикасының муниципаль служба турындагы Кодексының 19нчы маддәсе, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставының 50нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы карар бирде:

1. "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

Нурлат шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс дәгъвачылардан документларны 2015 елның 25 сентябреннән 14 октябрь 16.00гә кадәр Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының, Нурлат шәһәре, Совет ур., 98 адресындагы бинасында 8.00дән 16.00гә кадәр кабул итәргә, шимбә-якшәмбе көннәреннән тыш, тел.: 2-91-11, факс: 2-06-42.

2. Конкурс комиссиясенә, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге вәкәләтле органының 14.11.2005 елгы №8 Карары белән расланган "Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, 2015 елның 15 октябрендә 14.00дә Нурлат муниципаль районы Советының Нурлат шәһәре, Совет ур., 98 адресындагы бинасында конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турындагы мәгълүматны Нурлат шәһәре Советына бирергә.

3. Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларны карау өчен 4 кешедән торган конкурс комиссиясе составын расларга (№1 кушымта нигезендә).

4. Әлеге карарны 2015 елның 25 сентябренә кадәр "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасында бастырырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне конкурс комиссиясе әгъзасы Т.З.Фадеевага йөкләргә.

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы рәисе Р.Ә.КУЗЮРОВ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

№6 **21 сентябрь 2015 ел**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең вәкәләтләре туктатылу, Нурлат муниципаль районы Советы вәкәләтләренең вакыты чыгу сәбәпле, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 37нче маддәсе, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28.07.2004 елгы №45-ЗРТ законның 26нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставының 46нчы маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурска дәгъвачылардан документларны 2015 елның 25 сентябреннән 14 октябренә кадәр Нурлат муниципаль районы Советының Нурлат шәһәре, Совет ур., 98, адресы буенча, 13нче кабинетта 8.00дән 16.00гә кадәр кабул итәргә, шимбә-якшәмбе һәм бәйрәм көннәреннән тыш, тел.: 2-06-19.

2. Конкурс комиссиясенә Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларны конкурс сайлап алуы буенча, гаризалар бирү төгәлләнгәч, 30 көн дәвамында утырыш уздырырга һәм 2015 елның 13 ноябреннән дә соңга калмыйча конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турындагы мәгълүматны муниципаль район Советына бирергә.

3. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларны карау өчен 6 кешедән торган конкурс комиссиясе составын расларга.

4. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларны карау өчен 3 кешедән торган конкурс комиссиясе составының яртысын билгеләргә (№1 кушымта).

5. Әлеге карарны 2015 елның 25 сентябреннән дә соңга калмыйча "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасында бастырырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне район башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногмановага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы рәисе Р.Ә.КУЗЮРОВ

Соңгы ике карар буенча да кушымталарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтыннан карагыз.

ВАКЫТ. ВАКЫЙГА

ТАТАРСТАННЫКЫН САТЫП АЛ!

Себердә дә Нурлат шикәре белән чәй эчәчәкләр

Новосибирск, Омск, Томск, Красноярск, Яр Чаллы, Казан, Самара... Быел "Нурлат шикәре" җәмгыятендә җитештерелгән шикәр комы әнә шулай Россиянең төрле почмакларына таралачак.

Шикәр заводы сезонны, алдан планлаштырылганча, август азагыннан башлап җибәрде. Шөкер, басуларда татлы тамыр уңышы сөендерерлек, көннәр дә коры һәм кояшлы. Шуңа да кагат кырларына йөк машиналары Нурлат, Аксубай һәм Яңа Чишмә районнарыннан агыла тора – эшкәртеп кенә өлгер! Әлбәттә, бу көннәрдә заводта "кызу" эш өсте: яздан көзгә кадәр дәвам иткән зур ремонт эшләреннән соң көйле эш режимына кереп килүче заводның һәр почмагында куәтле механизмнар гөрелтесе һәм бар җирдә дә эссе пар һәм кайнар шикәр исе... Заводның өлкән инженеры Андрей Ефремовка ияреп, кагатлардан су агымы белән төрле чистартулар аша заводка җитештерүгә кергән чөгендернең шикәргә әверелү этаплары белән танышабыз.

– Заводта чөгендернең юлы чистарту һәм чөгендер ваклау бункерларыннан башлана, – дип "экскурсияне" башлап җибәрә ул.

Заводта сезон башыннан бирле 44 мең тоннадан артыграк чөгендер эшкәртелгән, 5 мең тоннадан артыграк шикәр комы җитештерелгән.

Биредә шундый өч чөгендер ваклау бункеры бар икән, аларның икесе быел шактый ремонт кичергән, берсе - яңа. Чөгендердән шикәр чыгу микъдары иң беренче чиратта әлеге процессның сыйфатына бәйле, шуңа да бу участокта мәшгуль булган IV разрядлы Дмитрий Романовның эше үтә дә җаваплы.

– Пычакларның һәрчак үткен, йомычкаларның сыйфатлы булуын кайгыртып торам, – ди ул. Биредә өч шундый чөгендер ваклау бункеры урнашкан булуын исәпкә алганда, аңа ничек өлгерергә туры килүен дә чамалавы кыен түгел.

Тигез чөгендер йомычкалары исә грабельле транспортер буйлап диффузия бүлегенә юл ала. Быел бу транспортерны да киңәйткәннәр һәм озынайтканнар заводта.

Чираттагы этап – диффузия бүлегендә. Биредә урнашкан диффузия аппараты чөгендер йомычкаларыннан шикәр согы алуга хезмәт итә. 40 метр озынлыгындагы гаҗәеп зур размерлы әлеге аппаратка ике ел рәттән этаплап зур капиталь ремонт эшләре үткәрелде.

– Аппарат көйле эшли, сезон башыннан бирле бер проблема да чыкканы юк, - ди компьютер аша бүлекчәдәге барлык параметрларны күзәтеп һәм көйләп торучы диффузия операторы Илнур Тямаев. Гаҗәеп зур диффузия системасына кагылышлы бар мәгълүмат та экранда чагыла. – Хәзерге вакытта сәгатенә 112 тонна чөгендер эшкәртелә. Барлык күрсәткечләр дә нормада.

ДМИТРИЙ РОМАНОВ ЧӨГЕНДЕР ЙОМЫЧКАЛАРЫНЫҢ СЫЙФАТЛЫ БУЛУЫН КАЙГЫРТА

Әмма чөгендер согы ул әле шикәр дигән сүз түгел. Кристаллы шикәр алганчыга кадәр ул дефеко-сатураций станциясендә төрле процесслар һәм фильтрлар ярдәмендә чистарту үтә. Бары шуннан соң гына пар станциясенә, аннан вакуум-аппаратларга китә. Беренчел продукт утфеле кайнатучы аппаратчы Рәсимә Бикбаева бу участокта мәшгуль. Ул махсус пыяла ярдәмендә вакуум-аппараттагы сыеклыкны утка якын китереп карый. – Сироп әзер түгел әле, - ди ул.

Әзер булган сироп продуктлар бүлегенә китә. Биредә шикәр комы кристаллары барлыкка килә һәм инде әзер продукт киптерелеп, фасовкалауга озатыла.

Әлбәттә, һәр процесс биредә эшләүче хезмәткәрләрнең күзәтүе һәм игътибары астында уза, чөнки бер генә этапта өзеклек килеп чыгу да тулы бер чылбырның өзелүенә китерергә мөмкин бит.

– Заводта күп нәрсә эшче кадрларның һөнәрмәнлегеннән дә тора. Сезонга әзерлек чорында ремонт һәм инвестиция программаларына 54 млн.нан артыграк сум үзләштерелде. Шуның нәтиҗәсендә бүгенге көндә тәүлегенә 2300 тонна татлы тамыр эшкәртәбез. Әмма бу чик түгел, тәүлеклек эшкәртүне 2500-2700 тоннага кадәр җиткерергә дигән бурыч куябыз, - ди заводның генераль директоры Игорь Сагайдак.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

СӘЛАМӘТЛЕК

Соң булганчы...

Быел районыбызның 4 кешесендә рак авыруы табылган. Әмма поликлиникага үзвакытында мөрәҗәгать итү аларның тулысынча сәламәтләнүен гарантияли: авыру башлангыч стадиядә билгеле булган.

Бернидән дә шикләнмәүче кешеләр үз авыруларын шулай тиз сизәрләр иде микән? Чөнки хәтта югары температура белән дә без өй шартларында көрәшәбез бит, ә табиблар янына хәлебез авырайгач кына барабыз. Ә бу очракта бер хатын-кыз һәм өч ир-ат үз диагнозлары хакында диспансерлаштыру узу нәтиҗәсендә белгәннәр.

– Медицина бик алга китте, – ди Нурлат хастаханәсенең гомуми практика табиблары бүлеге мөдире Ләйлә Фаттахова. – Ракны I һәм II стадиядә тапкан очракта, авыруны җиңәргә, кеше гомерен саклап калырга мөмкин дип ышанып әйтергә була.

2015 елда диспансерлаштыруны быел 21 яше тулган һәм алга таба Зәр ел аерма белән 24, 27, 30, 33, 36, 39, 42, 45 һ.б. яшьлек ир-атлар һәм хатын-кызлар үтә. Быел 8759 нурлатлы шундый табиблар күзәтүен үтәргә тиеш. Шуларның 5500дән артыгы тикшерү уза башлаган инде, 5000нән артыгы диспансерлаштыруны тулысынча төгәлләгәннәр. Бу шуның кадәр кеше кыйммәтле анализлар биргән, флюорография, маммография, УЗИ, ЭКГ үткән һәм үз сәламәтлеге хакында барысын да белә дигән сүз. Әмма шул ук вакытта табиблар кешеләрнең үз сәламәтлекләренә җитди карамауларын һәм диспансерлаштыру узарга бик ашыкмауларын да билгеләп үтәләр.

– Куркыныч факторларны белмәү гомер өзелүгә китерә, – ди Ләйлә Зарифовна. – Артык авырлык, югары кан басымы һәм холестерин дәрәҗәсе... Диспансерлаштыру йөрәк-кан авырулары килеп чыгуга нигез бирүче әлеге факторларны ачыклауга юнәлтелгән.

Быел диспансерлаштыру узуны гадиләштерү өчен Нурлат хастаханәсендә төрле ысуллар кабул ителде. Мәсәлән, эш көннәрендә тикшерү үтә алмаганнар өчен узган шимбәдә анализлар бирү, флюорография үтү, табибларга күренү мөмкинлегә булдырылды. Моннан 165 кеше файдаланды.

– Диспансерлаштыру кысаларында предприятиеләргә барып, тикшерүләр оештырабыз. Диспансерлаштыру яшендә булганнардан башта кан анализы алабыз, соңыннан, анализлар әзер булгач, бөтен җиһазлары белән табиблар бригадасы тикшерү уздырырга бара, - ди баш табибның поликлиника эшләре буенча урынбасары Вазыйх Гафуров. Шундый тикшерүләр шикәр заводы, "ТНП-Зүзәйнефть", почта, УТТ, НПБР һәм башка предприятиеләрдә, зур авылларда, ФАПларда оештырылды. Моннан тыш, график буенча, фельдшерлар да авыл кешеләрен мондый тикшерү узарга алып киләләр.

Шунысын да искәртик: диспансерлаштыру 2 этапта уздырыла, шуңа, анализлар бирдем, авыру таптылар, шуннан нишлисе дип аптырарга кирәкми.

– Анализлар Казанга җибәрелә. Әгәр тайпылышлар табылса, авыруны тагын бер кат тикшерүгә чакырабыз, кирәк булса, Казанга юллама бирәбез, – ди Вазыйх Гафуров.

Моннан тыш, диспансерлаштыру узуны уңайлырак итү максатыннан, май аеннан поликлиникада анализ бирү һәм ЭКГ үтү өчен аерым кабинет бирелде. Гомумән алганда, шартлар булдырылган, калганы кешенең үз сәламәтлеген кайгыртырга теләвенә бәйле. Мәсәлән, Ләйлә Зарифовна әйтүенчә, холестерины буенча кеше үзенең күпме яшәячәген, ә кан анализы буенча якынлашып килүче инфаркт турында белә ала. Димәк, һәр кешенең үз гомерен озынайту мөмкинлеге бар. Һәм моны соңга калмыйча башкарырга кирәк.

Гриппка каршы вакцина кайтты

Районга гриппка каршы "Гриппол Плюс" вакцинасының 3995 дозалык беренче партиясе кайтты.

Поликлиникадан алынган мәгълүматка караганда, балалар бакчаларына йөрүче 780 бала прививка алырга өлгергән инде. Бу чорда исә мәктәп укучыларын да кертеп 5700 баланы вакцинацияләү күздә тотыла. Бу сезонда сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле проект кысаларында 15000 доза вакцинаның кайтуы көтелә, ул шулай ук предприятие һәм оешмалар хисабына да кайтырга тиеш.

Моннан тыш, мәгариф, медучреждение хезмәткәрләренә, 60тан олыракларга һәм студентларга да прививка ясамакчылар.

Чагыштырыгыз, уйлагыз, сайлагыз!

Быел 80 нурлатлы социаль хезмәтләр алу хокукын кире кайтарган, шуларның 29ы сайлауны 16 сентябрьдән соңгы чорда ясаган.

Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, ташламага ия гражданнарга 1 октябрьгә кадәр акча яки социаль җыелма алу турында төпле фикергә килергә кирәк. Акчаны сайлаганда, кулга ай саен 716 сум акча керәчәк. Ә дәвалану буенча чыгымнар күпкә артыграк.

ШИКӘР ЧИРЕ. Беренче тип диабеттан дәвалану якынча 23 меңнән алып 53 мең 700 сумга төшә. Ә икенче тип диабеттан дәвалау чыгымы 7 мең сумнан 62 мең сумга кадәр.

ЯМАН ШЕШ АВЫРУЛАРЫ. Күкрәк бизе яман шешеннән дәвалану – 1,4 меңнән алып 1 миллион 265 мең сум һәм аннан да күбрәк. **ҮПКӘ ЯМАН ШЕШЕ** – 42 меңнән алып 1 миллион 34 мең сумга кадәр.

БРОНХИАЛЬ АСТМА ЧИРЕ. 3 меңнән башлап 32 мең сумга кадәр чыгымнар сорый.

Кайчакта бер төргәк дару да 50 мең сумнан 1,5 миллион сумга кадәр тора. Бу уңайдан сораулар-ны Пенсия фондының "кайнар линия" телефонына шалтыратып бирә аласыз: (843) 279-27-27.

СӘХИФӘ ЯЗМАЛАРЫН Сирень СӘМӘРХАНОВА ӘЗЕРЛӘДЕ

КӨН СУЛЫШЫ

ТАТАР ЯЗМЫШЫ

Шәҗәрә бәйрәме нәселне бергә җыйды

Узган атна ахырында Бикүле авылының иске зиратында җирләнгән Шаһиморат мулла каберенә яңа таш кую һәм кабер тирәсен төзекләндерү чарасы мәрхүмнең зур нәсел дәвамчылары өчен олы шәҗәрә бәйрәменә әверелде. Бәйрәм бер гөлнең ике ботагы сыман таралып, озак еллар бер-берләреннән хәбәрдар булмый Татарстанда яшәгән танылган Моратовлар һәм Төркиядә төпләнеп гомер кичергән тарихчы, олы галим Әгъдәс Нигъмәт Курат нәселләрен бергә җыйды.

Шаһиморат–Равил Фатих улы Моратовның бабасының әтисе, имам Нигъмәтулланың өченче никахтан туган улы. Аннан тамыр алган янә бер нәсел–Әгъдәс Нигъмәт Курат – Шаһиморатның икенче никахтан туган җәдитче Таһир мулла улы. Тумышы белән Чирмешән районының Бәркәтә авылыннан булган егет Бөгелмә рус гимназиясен тәмамлаганнан соң, укуын дәвам итәргә теләп 1922 елда Германиягә китә. Анда ниятен тормышка ашыру мөмкинлеге тапмыйча, 1924 елда Стамбул шәһәренә китеп, университетка укырга керә. Анда укыганда ук фәнни эш белән шөгыльләнә башлый, ә 1928 елда университетны тәмамлап, Европада укуын дәвам итәргә карар кыла. Бер елдан соң Германиягә китә, 1933 елда диссертация яклап, философия фәннәре докторы исемен ала һәм Стамбул университетында укыта, фәнни эш белән шөгыльләнә башлый. Чит илләрдә еш булу, архивларны өйрәнү, уртак фәнни эзләнүләрдә катнашу, саммитларда, югары дәрәҗәдәге конференцияләрдә чыгышлар ясау, фәнни язмалар бастыру– галим, тарихчы Әгъдәс Нигъмәт Куратны Бөтендөнья галимнәр даирәсендә танылуга китергән юл әнә шулай салына. Ул – 12 телне үзләштергән, 15 китап чыгарган, 70тән артык фәнни язмалар бастырган профессор, тарихчы, философ. Аның хезмәтләре нигездә Көнчыгыш Европа төрекләре тарихына, Россия һәм Төркия мөнәсәбәтләренә багышланган. Кызганыч, дистәләгән чит илләрдә булган галим туган җирен кайтып күрә алмыйча, 1971 елда автоһәлакәттә һәлак була. Әмма татар каны үзенекен итә: аның оныкларына бабалары эзе буйлап үтәргә насыйп була. Бикүле зиратында табылган таш эзеннән ТР Фәннәр Академиясенең Шиһап Мәрҗани исемендәге тарих институты үткәргән эзләнүләр нәтиҗәсендә ачыкланган туганлык җепләре Моратов – Куратларда бер-берләре белән якыннан аралашу, нәсел бәйләнешләрен нык ыгыту теләгә уята. Тәүге очрашу узган ел була. Әгъдәс Нигъмәт Куратның оныкасы – Стамбул технологик университеты укытучысы Идел ханым һәм оныгы – төрек лицеенда инглиз теле укытучысы Каан әфәнде үткән ел туганнары белән күрешүдән тыш, Бәркәтә авылында, КФУда очрашулар үткәрәләр, илгә танылган бабалары турында күп мәгълүмат биреп, үз тамырлары турында мәгълүматны баетып китәләр. Быел исә алар игелекле – кабер ташын яңартуга бәйле шәҗәрә бәйрәмендә күрешергә сәйләшкәннәр, һәм Төркиядән дә, Татарстаннан да өч буын туганнар очрашу урыны итеп ерак бабалары җирләнгән Бикүле авылын сайлыйлар. Чара тулаем Бикүле авылы халкы өчен дә зур һәм тәрбияви вакыйга булды. Ул зират өстендә таш кую, Коръән аятьләре укып дога кылу белән башланып, нәзер корбаны аш мәҗлесендә дәвам итте, авыл мәчетендә тәмамланды. Табын артына җыелган 100дән артык авыл өлкәннәре догалы сый-нигъмәттән авыз итеп рәхмәт укысалар, килә алмаучы картларның өлеше өйләренә таратылды, мәчеткә сәдакалар тапшырылды. Мәктәп китапханәсендә хәзер Әгъдәс Нигъмәт Куратның биш томлыгы сакланачак. Ә галимнең Алтын Урда һәм Россиянең 1917 елга кадәрге тарихларына багышланган ике зур хезмәте ТР Фәннәр Академиясенең Тарих институты галимнәре тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп Казанда басылачак икән. Мәҗлес әнә шулай үзе нурлы, үзе мәгънәле аралашу чарасына әверелде. Өч дистәләп туганнар үзара аралашудан тыш, авыл халкы истәлекләреннән берәмтекләп үткәннәре турында мәгълүмат тупладылар. Бу аларның һәммәсе өчен дә мөһим иде.

– Әгәр без үз шәҗәрәбезне белмибез икән, безнең балаларыбыз, оныкларыбыз безне хәтерләмәячәк. Буыннар чылбыры нык булсын өчен, хәтерле булырга, тамырларыбызны белергә кирәк,– диде бу эшләрнең башында торучы Равил Фатих улы Моратов. Бу сүзне Төркиядән кайткан Әгъдәс Нигъмәт Куратның оныклары Идел ханым һәм Каан да куәтләделәр. Чыгышлар, әлбәттә, чарада катнашучы оныклары колакларын һәм күңелләрен дә читләп үтмәгәндер. Ә Бикүле авыл җирлеге башлыгы Рияз Садыйков тәкъдиме шунда ук хуплау да тапты: быелдан Бикүле мәктәбендә "Үз шәҗәрәңне төзе" дигән конкурс игълан ителәчәк, аның иң уңышлылары республика бәйгесенә дә юлланачак.

Шәҗәрә бәйрәме әнә шундый дәвамлы матур эшкә нигез дә салды әле. Ә авыл халкының кунакчыллыгыннан канәгать булган кунаклар Биләргә, аннан Болгарга юл тоттылар. Үз тамырларын, татар халкы тарихын тирәнтен белергә теләүче милләттәшләребез өчен иң игелекле һәм мәгълүматлы юл шунда ята ләбаса.

ЗУР НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

ҺӘНӘРИ БӘЙРӘМ

Бала күңеленә игелек салучылар

Бу якшәмбедә районның барлык мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәре – тәрбияче көнен билгеләп үтәчәк.

"Чишмәкәй" балалар бакчасы өчен быелгы һөнәри бәйрәм икеләтә сөенечле. Чөнки әлеге мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" республика конкурсында җиңү яулады.

1968 елдан бирле эшләүче "Чишмәкәй" балалар бакчасына бүген 10 төркемдә барлыгы 260 бала йөри. Берсе – татар төркеме. Бакчага йөрүче нәниләргә татар телен тәрбияче Рәслимә Мостафина өйрәтә.

– Әлеге бакчада тәрбияче булып 24 ел эшлим, - ди балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча тьютор. – Балаларны гына түгел, районның рус телле тәрбиячеләрен дә татар теленә өйрәттем. Әлеге юнәлештә Казанда махсус курслар уздым.

Шул еллар эчендә тәрбияче Рәслимә Нурулловна проект эшен дә яклый. 2012 елда бакча "Татарча сөйләшәбез" укыту-методик комплектын өйрәтү буенча республика масштабында эксперименталь мәйданчык була, 2013 елда әлеге проект тормышка ашырыла. Комплектның проект авторлары З.Зарипова һәм Р. Исаева катнашында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча республика зона семинары да әлеге балалар бакчасы базасында уза.

– Балалар атнасына 3 тапкыр дәресләрдә татар телен өйрәнәләр,- ди Рәслимә Нурулловна. – Бу эштә әти - әниләрдән башка гына булмый, алар актив катнашучылар. Рус телле балалар берничә җөмләдән диалог төзеп сөйләшә һәм үзара татарча аралашалар.

Рәслимә Нурулловнаны мәктәпкә, башка учреждениеләргә дә эшкә чакыргалаганнар. Әмма ул яраткан балаларын, коллективын ташларга теләмәгән.

Язмыш Рәслимә Нурулловнаны төрле яклап сыный. Тормыш иптәше сукыраю, аннан үлеп китүен, ике кызын аякка бастыру мәшәкатьләрен дә кичерә ул. Сабыр, чыдам һәм игелекле кешене Ходай Тәгалә ярдәменнән ташламый. Бүген ул әнисенә һәм каенанасына бер дигән кыз, ә балаларына яраткан әни булып гомер кичерә.

– Тәрбияче һөнәре җаваплы да, шул ук вакытта кызыклы да, – ди тәҗрибәле тәрбияче. – Мәктәпкәчә яшь – бала тормышындагы аеруча мөһим һәм җаваплы чор бит.

Имин балачак һәм һәр баланың алдагы язмышы Рәслимә Нурулловна кебек тәрбиячеләрнең зирәклегеннән, сабырлыгыннан да тора.

РӘСЛИМӘ МОСТАФИНАНЫҢ ДӘРЕСЛӘРЕНӘ БАЛАЛАР ТЕЛӘП ЙӨРИ

Зилия ӘКСАНОВА

ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Акциягә кушылдылар

Сишәмбе көнне билгеләп үтелгән Бөтендөнья автомобильсез йөрү көнендә районның беренче затлары шәһәр халкына үрнәк күрсәттеләр.

Мисал өчен, бу көнне район башлыгы Равил Кузюров эшкә җәяү килде. Акциягә районның башка җитәкчеләре, район башкарма комитеты, балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре, балалар сәнгать мәктәбе хезмәткәрләре дә кушылды.

– Сәламәтлек өчен бик файдалы, һәркемгә тәкъдим итәм, - диде район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин. – Мөмкинлек чыкканда, эшкә машинасыз йөрергә тырышам.

Автомобильсез йөрү көне бөтен дөньяда 1973 елдан башлап билгеләп үтелә. Бу көнне кешеләргә хәрәкәтнең экологик төрләрен – җәяү яки велосипедны сайлау тәкъдим ителә. Нурлатта акция 16-22 сентябрьдә Европа мобильлеге атналыгы кысаларында узды. Ул сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм шәһәрнең экологиясен яхшыртуга юнәлдерелгән иде.

Зилия ӘКСАНОВА

АКЦИЯГӘ НУРЛАТЛЫЛАР ТЕЛӘП КУШЫЛДЫ

УҢЫШ

11.1 НОМЕРЫ АСТЫНДА ЧЫГЫШ ЯСАГАН ОЛЕГ АЛЕКСЕЕВНЫҢ ДЕБЮТЫ УҢЫШЛЫ БУЛДЫ

Нурлат егете дөнья рекорды куйды

Урманчылар көне кысаларында Казанда урман кисүчеләрнең III Россия Чемпионаты үтте.

"Казан-Арена" стадионында илнең 30 иң яхшы урман кисүчеләр командасы көч сынашты. Татарстанны исә составында нигездә Нурлат урман хуҗалыгы хезмәткәрләреннән торган команда тәкъдим итте.

– Безнең хезмәткәрләрнең әзерлегә күпкә яхшырак, – ди Нурлат урман хуҗалыгы директоры Спартак Еливанов. Татарстанның җыелма командасына безнең урман хуҗалыгыннан 3 урман кисүче, Лубянскныкыннан 1 юниор керде.

Чемпионат нәтиҗәләре урман хуҗалыгы директоры сүзләренең хаклыгын раслады. Урман кисүче Олег Алексеев "Агач кисү" өлешендә 660тан 660 очко җыеп, дөнья рекорды куйды.

Россия чемпионының мондый төр ярышларда беренче катнашуы. Ул, кем әйтмешли, тәҗрибә генә туплый әле – урман хуҗалыгының Тимерлек участогында ике ел эшли, бирегә армиядән соң килгән. Ә менә чемпионатта катнашкан тагы бер урман кисүче, Чулпан участогыннан Станислав Марининның эш тәҗрибәсе дә, мондый бәйгеләрдә катнашканы да бар. Бу юлы да ул яхшы нәтиҗә күрсәтеп, "Урман кисү" өлешендә 3нче урын алды. Әлеге нәтиҗәләр Татарстан командасына пьедесталның икенче баскычына менәргә мөмкинлек биргән дә. Ә бу үз чиратында дөнья чемпионатында катнашу өмете бирә.

– Киләсе елның июлендә Россиянең шундый ук чемпионаты узачак һәм 2015 һәм 2016 ел чемпионатлары нәтиҗәләре буенча, Россия командасы формалаштырылачак. Ул исә Польшада үтәчәк дөнья чемпионатында катнашачак, – ди Спартак Еливанов. Әзерлек өчен әле вакыт бар. Кем бәлки, бәлки, бәхет безгә тагы бер кат елмаер һәм дөнья рекорды куйган Олег Алексеев тагы дөнья чемпионы титулын да яулап куяр?..

Сирень СӘМӘРХАНОВА

КЫСКАЧА

Чираттагы утырыш узды

